# Иң күңелле чак

Җәйне көтәбез
Кайчан җитә, дип.
Җиткәч куркабыз
Үтеп китә, дип

Җәй үзе шуны
Сизгән шикелле
Кыскарта төнне,
Озайта көнне.

Кояш соң бата,
Төннән таң ата;
Айга эш тә юк.
Ял итеп ята.

Кояшка эш күп:
Ул таңнан тора.
Иген үндыра,
Безне кыздыра.

Безгә миләшләр,
Җиләкләр пешерә,
Яхшылык кына
Эшли кешегә.

**Бари Рәхмәт**

# ЖӘЙ ТУРЫНДА СЫНАМЫШЛАР

Әгәр сандугач төне буе сайрый икән, икенче көнне көчле җил булачак.

Июнь ае җылы булса, уңыш яхшы булачак.

Июнь аенда яңгырдан соң Салават күпере пәйда булса, һава торышы бик озак вакыт җылы булачак.

Төнлә яшен еш булса, уңыш мул булачак.

Әгәр тургай үз оясын җирдә кора икән, җәй бик коры булачак, ә агачта корса, яңгырлы була.

Әгәр миләш соң чәчәк ата икән, көз озын булачак.

Июньдә томан еш булса, гөмбәләр күп булачак.

Карлыгач җәй башлый, сандугачтан җәй тәмамлана.

Июнь аенда чәчәкләр чәчәк ата, сандугачлар җырлый, июнь аенда күңелле, ә ризык аз.

Июньдә иртән су буйлап томан агыла икән, кояшлы яхшы һава булачак.

Чәчәк атучы миләшкә бал кортлары күп җыелса, икенче көнне һава торышы яхшы булачак.

Августның беренче атнасында тотрыклы һава торышы саклanса, кыш озын һәм карлы булыр.

Томан озак таралмый торса - аяз көнгә.

Август яңгырсыз килсә, җылы һәм коры көзгә.

Августта бәс төшсә, иртә кышка ишарә.

Августта берничә тапкыр яшен булса, көз озак булыр.

Җылы, яңгырлы август - гөмбә уңышына.

# ЖӘЙ ТУРЫНДА ТАБЫШМАКЛАР

Ашлыклар үсте,
Башаклар пеште;
Кояш пешерә,
Тиргә төшерә.
Халык ашыга,
Китә басуга,
Урагын ура,—
Бу кайчак була? *(Җәй)*

***

Алсу битле кыз үсте,
Кызарып җиргә төште. (*Алма)*

***

Түгәрәк-түгәрәк шар кебек,
Кызыл-кызыл кан кебек;
Әчедер дә татлыдыр,
Йотыйм дисәң ташлыдыр. *(Чия*

***

Жимешем кып-кызыл була
Бу шатлык минем өчен!
Чөнки кышкы салкында да
Үзгәрми минем төсем. *(Миләш*)

***

Үзе шардай, эче кандай, тәме балдай. *(Карбыз)*

***

Өе яшелгә буялган, эчендә кызыл чаршау. (*Карбыз)*

***

Озын курай үләндер, кызыл алка элгәндер. (*Кура җиләге)*

***

Иелә, бөгелә, ак мамыгы түгелә, кара күзе күренә. *(Шомырт*)

***

Урманда кара төймәм эленеп тора. *(Шомырт)*

***Менә җәй килде. Агачларда яшел-яшел яфраклар үсте. Чыпчыклар матур иттереп сайрый башладылар. Көннәр җылынып китте,озынайды. Яңгырлар ява башлады. Авылга кайткач җиләк җыябыз,печән чабабыз.***



